СӨЯ ГОМЕРНЕ, СӨЯ ХАЛЫКНЫ, СӨЯ ХАЛЫКНЫҢ ДӨНЬЯСЫН!

# ДУСЛЫК

ОКТЯБРЬ РАЙОНЫНЫҢ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГАЗЕТАСЫ.
ОБЩЕСТВЕННО-ПОЛИТИЧЕСКАЯ ГАЗЕТА ОКТЯБРЬСКОГО РАЙОНА.

Газета 1931 елның 8 июленнән бирле чыга. | №66 (7239) | 8 июнь, 1991 ел. ШИМБӘ | Бәясе 4 тиен.

## 12 июнь—ТССР Президентының сайлау көне

# Сайлау комиссияләре эштә

**Татарстан Президентын сайлау көне, 12 июнь якынлаша. 33 номерлы Октябрь сайлау округы буенча район сайлау комиссиясе рәисе Н. Х. АБДУЛЛИН белән әңгәмәбез шул хакта.**

**КОРР. Нәбиулла Хәйруллович, беренче тапкыр Президент сайлау уңаеннан шәхси кичерешләрегез белән уртаклашсагыз иде.**

**Н. АБДУЛЛИН.** Суверен җөмһүриятебезнең башлыгын сайлау сөенечле хәл, әлбәттә. Ләкин икенче ягын да әйтү кирәк, вакыт бик кысан, бөтенесенә айдан ким срок бирелде.

**КОРР. Бүгенге этапта комиссиянең бурычы нидән гыйбарәт?**

**Н. АБДУЛЛИН.** 17 майдан башлап комиссиянең өч утырышы үтте. Соңгысын 3 июньдә уздырдык. Анда Биләр-Озеро авыл Советының, аның территориясенә урнашкан участокларның 12 июньгә әзерлеге мәсьәләсе каралачак. Дүртенчесе тавыш бирү тәмамланганнан соң үткәрелә.

Округ сайлау комиссиясе членнары конкрет участокларның сайлауларга хәзерлеген контрольдә тоталар. Бу мәсьәләдә сораулар, проблемалар туа икән, аларны урында хәл итү чараларын күрәләр.

Урыннарда 12 июньгә хәзерлектә участок сайлау комиссияләре эш алып бара. Оештыру һәм тәэмин итү чаралары өчен шулай ук халык депутатларының авыл Советлары да җаваплы.

**КОРР. ТССР Президенты белән берлектә РСФСР Президентын сайлау үткәрелә бит. Безнең җөмһүрияттә аны үткәрүгә бәйле хәзерлек алып барыламы?**

**Н. АБДУЛЛИН.** Мәгълүм булганча, ТССР территориясендә РСФСР дәүләт башлыгын сайлау ирекле, ягъни анда теләгән гражданнар катнаша ала. Югары Совет шул категория халыкның үтенечен исәпкә алып, кабул итте дә карарны.

**КОРР. Аны үткәрү дә сезнең комиссиягә үк йөкләтелгән. Бу мәсьәләгә ачыклык кертүне сорап редакциягә мөрәҗәгать итүчеләр бар.**

**Н. АБДУЛЛИН.** Әйе, ТССР Президентын сайлау буенча төзелгән комиссияләр бу мәсьәләдә теләүчеләргә булышлык күрсәтергә тиешләр. Сайлауга килгән гражданнар арасыннан РСФСР Президентын сайлауда теләк белдерүче була икән, аңа бюллетень бирәләр.

Ике президент өчен исемлекләр аерым була. Әйтик, тавыш бирүче иптәш үз җөмһүриятебез башлыгын гына сайларга тиеш. Ул барлык исемлек буенча бюллетень ала, шул хакта имзасын куя. Ә РСФСР Президенты өчен тәкъдим ителгән исемлектә имзасы булмагач тавыш бирүдә катнашмаган санала.

**КОРР.: Сайлау көнендә килүче, китүчеләр була.**

**Н. АБДУЛЛИН.** Китүчеләргә учеттан төшерү талоны бирелә. Шуның нигезендә алар яңа урында тавыш бирүдә катнаша алалар. ТССР гражданнары җөмһүрияттә үзләренең һәм РСФСРның дәүләт башлыгын сайлауда катнаша алалар. Чит өлкәләргә чыкканда якташларыбыз РСФСР җитәкчесе өчен генә тавыш бирергә хокуклылар. Чит өлкәдән килүчеләр дә РСФСР гражданнары хокукларыннан файдаланырга, Россия лидеры өчен тавыш бирергә мөмкин.

**КОРР. Россия халык депутатлары съезды 12 июньне ял көне итеп игълан итте. Ул бездә ничек булачак? Халыкны бу мәсьәлә дә кызыксындыра.**

**Н. АБДУЛЛИН.** ТССР Югары Советында бу хакта сүз булды. Бездә ул эш көне санала, үзгәртү булганы юк. Вакыт мәсьәләсендә, соңгы мәгълүматлар буенча үзгәреш бар. Тавыш бирү иртәнге 6 сәгатьтән башлана һәм кичке 10 га, ягъни 22 сәгатькә кадәр дәвам итә.

Сүз уңаеннан барлык районлашларыбызның җөмһүриятебез Президентын сайлауда активлык күрсәтәсенә, гражданлык бурычын үтәүдә һәркемнең катнашасына ышанам.

**КОРР. Әңгәмәгез өчен рәхмәт, Нәбиулла Хәйруллович.**

# Бюро утырышы

Күптән түгел КПСС райкомы бюросының киңәйтелгән утырышы булып үтте. Анда башлангыч партия оешмалары секретарьлары катнашты. Утырышта КПСС райкомының беренче секретаре Х. Х. Морадыймов КПСС сафларына кабул ителгән бер төркем яшь коммунистларга тантаналы төстә партия билетлары тапшырды. Алар арасында «Рассвет» совхозы баш инженеры Х. З. Бикиев, шәһәрнең 2 нче мәктәп укытучысы Н. П. Липатов, «Заря» колхозы шоферы В. А. Акмуллин, «Комбайн» колхозы склад мөдире М. Г. Зәйниев һәм башкалар бар иде.

Бюрода район башлангыч партия оешмаларында членлык взносларын түләү һәм отчет бирүнен торышы мәсьәләсе каралды.

КПСС райкомы бюросы членнары һәм катнашучылар алдында КПСС райкомының беренче секретаре, район Советы рәисе, ТССР халык депутаты ТССР Югары Советының IV сессиясе йомгаклары буенча чыгыш ясады. Башлангыч партия оешмалары алдында торган бурычларга тукталды.

Бюро тикшерелгән мәсьәләләр буенча тиешле карарлар кабул итте.



**Рәсемдә: «Сөлчә» совхозы дуңгыз караучысы Александр Николаевич Федоров. Хуҗалыкта ул уңган, тырыш кеше буларак билгеле. Шуңа күрә коллективта да ул хөрмәткә лаек.**

**Н. Азизов фотосы.**

# Әзерлек әйбәт

Иске Әлмәт авыл Советы территориясендә яшәүчеләр сайлау кампаниясендә һәрчак актив, аңлы катнашалар. Бу—әлбәттә, алдан тиешле аңлату-агитация эшләре алып баруның нәтиҗәсе. Быел ТССР һәм РСФСР президентларын сайлауга әзерлек барышына да без шундый ук җаваплылык белән карарга тырыштык. Участок комиссиясе үзвакытында оештырылды. Аның рәисе—укытучы Галимҗан Һадиевич Хамматов бик җаваплы иптәш. Комиссия планын үзвакытында төзеде, утырышларын үткәрде. Президент сайлау турындагы законны өйрәнделәр, теләсә нинди сорау буенча сайлаучыларга җавап бирерлек мәгълүматлы иптәшләр алар. Хәзер сайлау алды мәшәкатьләренең соңгы этабы бара инде. Бездә 15 округтан 625 сайлаучы теркәлде. ТССР Президентын сайлау буенча исемлек халык игътибарына куелды, һәркем аннан үзен барлый ала. Авыл китапханәсендә сайлаулар календаре куелган. Гомумән, сайлауларга әзерлекнең төп үзәге—авыл культура йорты. Биредә агитаторлар халык белән аралашалар, Президентлыкка кандидатның биографиясе белән танышалар. Сизелеп тора: кешеләр бу сайлауда безнең өчен Татарстан ССР Президентын сайлауның беренче чиратта мөһим булуларын аңлыйлар. Ә РСФСР Президентын сайлау—анысы һәркемнең ирек эше, ул безне аз кызыксындыра. Шуңа да республика Президенты кандидатурасы биографиясе, эшчәнлегенә карата кызыксыну урынлы. Сүз уңаеннан, без бу юнәлештәге күрсәтмә материалларны шактый соң алдык. Шуңа да хәзер аның белән халыкны радио аша да таныштырырга уйлыйбыз. Хәзер бит элеккечә формаль тавыш бирүләр бетте, һәркем үз хокукын уйлап кулланасы итә.

Бүген сайлау участогы да тулы хәзерлектә диярлек. 3 кабина әзерләнде, 5 урна булачак. Йөри алмаучылар өчен урынга барып сайлату да алдан ук кайгыртылган. Соңгы вакытта без сайлауларга чакырып халыкка открыткалар язуны гадәткә керткән идек. Комиссия члены, китапханәче З. Тахиятуллина быел да шундый чакырулар әзерли. Сүз уңаеннан, бу бик уңайлы, сайлаучыларга да бик ошый, сайлауга активлык белән җыелалар. Хәер, авыл кешеләре 12 июнь көнне болай да сайлау участокларына ашыгырлар дип уйлыйбыз. Чөнки бу—безнең республикабыз язмышында зур роль уйнаячак политик кампания бит.

**И. ЯҺУДИНА,**

Иске Әлмәт авыл Советы рәисе урынбасары.

## Эш тәмамланып килә

**Мөгезле эре терлек симертү буенча хуҗалыкара берләшмә.**

Хуҗалыкта 200 гектар чөгендер җире исәпләнә. Аны беренче кат эшкәртү тәмамлану алдында инде. Чөгендер игү звенолары җитәкчеләре Ш. Яруллин һәм З. Мөхәммәтов татлы тамыр уңышын мул алу өчен бөтен технологик таләпләрне төгәл үтәргә тырышалар. Чөгендерне сирәкләүдә эшләүче хатын-кызларның максаты да шундый. Алар быел 5әр гектарлы участокларны эшкәртәләр. Берләшмә эшчеләренә ярдәмгә авыл интеллигенциясе, контора хезмәткәрләре һәм башкалар да чыкты.

**Р. ШӘЙХЕТДИНОВ.**

# Ярышып эшләделәр

Быел Хафизов исемендәге колхоз сарыкларның йонын кыркуны 4 көндә төгәлләде. Барлыгы 1506 баш сарыкның йоны алынды.

Әлеге эшне I—II класслы осталар башкарды. Азат Морадыймов, аның улы Илһам, Харис Җәлалов, Галимҗан Ишмөхәммәтов зур тырышлык куеп эшләделәр. Азат Вәлиевич Морадыймов көн саен 70—91 баш сарыкның йонын кыркуга иреште. Илһам, Харис, Галиҗан да көнлек нормаларын арттырып үтәп килделәр.

Колхоз идарәсе йон кыркy осталарының эшенә йомгак ясап, урыннар билгеләде һәм аларга акчалата бүләк тапшырды. Беренче урынны А. Морадыймов алды һәм аңа 50 сум күләмендә акча бирелде. Икенче урынга аның улы Илһам чыкты.

Әнә шулай, кызыксындыру чаралары да кулланылгач, эш сыйфатлы һәм кыска срокта төгәлләнде.

**Т. ДЕРБЫШЕВ.**
**Хәбәрче.**

# «Кечкенә Алиягә булышыгыз»

«Дуслык»та чыккан шул исемдәге мәкалә безнең күптармаклы производство предприятиесендә эшләүчеләрнең һәммәсен тетрәндерде. Гөнаһсыз сабыйга ярдәм итү теләге белән предприятие аның исемендәге счетка 1 мең сум акча күчерергә карар кылды. Моннан тыш предприятие работниклары үзләре дә аңа булышлык күрсәтергә теләк белделәр: 10 ар сум иганә җыярга булдылар. Шулай итеп, без 2 мең сум акчаны нәни Алиягә юллыйбыз. Терелә күр, Алия! Безнең өчен аяз күк, тыныч тормыш һәм сәламәт балаларыбыздан да зуррак сөенеч юк.

**Н. СИДОРОВА.**

**Бөек Ватан сугышы башлануның 50 еллыгына карата**

# Чирек сәгатьлек тукталыш

(ОЧЕРК)

Сәлим бөтенесен алдан минутына, секундына кадәр исәпләп, хәзерләнеп куйган иде, ит комбинаты янындагы переезд турына җиткәч, поезд барган уңайга җиргә сикерде. Состав туктаганчы, 2—3 минут узачак әле, димәк, аның карамагында унбиш минутлап вакыт бар. Секундлар эчендә әллә ниләр эшләп өлгерергә әзер солдат өчен чирек сәгатьлек тукталыш озын срок. Ул вакыт эчендә Сәлим кардәш тиешле Вәлиәхмәт абыйсын күреп, авылда калган әти-әнисенең, туганнарының хәлен, солдатча әйткәнчә, иркенләп белешә ала.

17 яшенә кадәр авылдан чыкмый яшәгән, иң ерак киткән арасы район үзәге Норлат станциясеннән ары булмаган егетнең сагынулары чиктән ашкан иде бу минутларда. Норлат аркылы узасыларын белгәч, авылда яшәгән чаклары: әнисенең назлап эндәшүләре, иркәләп йокыдан уятулары, җидееллык мәктәптән соң колхозда яшьтәшләре белән шаярып-көлеп эшләп йөрүләре, сугыш башлану турында шомлы хәбәр, Чулпан МТСында «Коммунар» комбайнында ярдәмче булып эшләгән чаклары, заманалар авыр һәм көнелләре боек булса да, яшьләрнең кичке уеннарында егетләр һәм кызлар җыелып уздырган уеннар балачакның ерак, татлы истәлеге булып күз алдыннан үтте аның. Авылда һәрчак үткен, кыю, яшьтәшләренең игътибар уңында торган егет вакытның үткәнен сизми дә иде, хәрби хезмәткә чакырылганнан соң үткән ел ярым гомер аның өчен коточкыч озын булып тоелды. Ул күпкә җитдиләнде, олыгайды: Амурдагы Комсомольскида полк мәктәбе тәмамлады, Кытай чигеннән 60 километр гына ераклыктагы Уссурийскида (ул чакта бу шәһәр Ворошилов-Уссурийск дип атала иде) авточастьтә хезмәт итте. Аннан аларны техникасыз гына вагоннарга төяп озаттылар. Фронтка дип уйлаганнар иде, Түбән Тагилга җиткәч төшәргә боерык булды. Аларны танк йөртергә өйрәтә башладылар. Кышкы чатнама салкыннарда марш-бросоклар ясап сынау полигоннарына йөртеләр. Шундый өйрәнүләрнең берсендә аның аяклары туңып киез итегенә ябышты. Солдат хезмәте җиңел түгел. Анда әти-әниеңнең ягымлы эндәшүен, кызгануын көтәргә юк, лаеш шулпасын җитәрлек эчәсең: шуңа үткән ел ярым Гафуров өчен бөтен бер гомер шикелле озын тоелды...

Туган як тукталышында кемне дә булса күреп калу теләге аның күңелендә Чишмә тимер юл узелын үткәч уянды. Уралмаштан Т-34 танкларын кабул итеп платформаларга төяп фронтка озатканда алдагы маршрут—Казан әллә Сызрань аша китәселәрен танк йөртүче, мыегы да чыгып өлгермәгән сержантка кая, аның өчен арада иң өлкән офицер, рота командирына да билгеле түгел иде. Башкортстанның Чишмә узелында Сызрань юлына борылгач, туган як аркылы узасылары, ниһаять ачыкланды. Состав су, ягулык, азык-төлек алырга тукталса, туганнарыннан кемне дә булса күрәсе, әниләренең ничек көн күрешен сорашасы (цензура бит сау-исәннән артыгын уздырмый) килеп китте. Бу гына да түгел, ул бит хәзер фронтка, ут эченә китте—әллә кайта, әллә юк, билгесез—саубуллашып каласы килү барыннан көчле.

Фронтка баручы хәрби составларга һәркайда «Яшел урам», күп станциядә поезд тукталып та тормый. Әмма Норлатка туктыйсы, су алачагы билгеле булды. Моның өчен составка 10—12 минут вакыт кирәк. Аңа кадәр Сәлим икенче мәктәптә урнашкан госпитальдә эшләүче Вәлиәхмәт абыйсын күреп үзе турында хәбәр итеп, авылдагылар хәлен белешеп өлгерә ала.

Ул солдат чыныгуын әйбәт узган. Ерак Көнчыгышның капризлы табигатенә күнеккән, физзарядка белән шөгыльләнгән яшь танкист өчен икенче мәктәпкә кадәр ара еракмы соң—өч минут узып өлгермәде, барып җитте. Ишек төбенә җиткәч, ары-бире күз ташлап алды да эчкә үтте.

—Мне Вафина надо было,—диде ул беренче очраган халатлы хатын-кыздан.

—Какого Вафина?—Тыны кысылган солдатка карап, аңлый алмый торды тегесе.

—Нинди Вафин?Кем булып эшли?—дип икенче татар апа килеп кушылды әңгәмәгә.

—Вәлиәхмәт исемле, ул биредә эшли..

И, балакай, ул яңа гына пекарняга ипи алырга китте.

Эх, насыйп түгел икән! Кайтмый калса, ул соңгы очрашулары хакында өйдәгеләргә сөйләр, аны шулай бергәләп искә алырлар дип уйлаган иде, язмаганны биләп буламы соң?!

Ул инде 5 минутлар узганын, кире узасы юлының килгәндәгедән озынрак булуын аңлый иде, борылды да ике баскычны бер итеп астагы катка йөгерде, урамга килеп чыкты. Тирә-юньдәге агач йортлар аңа таныш, малай чакта ике ел биредә яшәделәр бит.

Менә ул әтисе Салих салдырган райбашкарманың ике катлы агач бинасы (хәзер ул урында «Норлатнефть» НГДУсы конторасы почмагына борылды. Чехол кидерелгән ачык платформалар төягән состав тора әле. Шөкер, куркыныч узды: сугыш чорында частеңнән калуның ни аңлатканын яхшы белә бит ул: трибуналга биреп хөкем итүләре бар. Атмасалар да, штраф батальонына озатулары бик ихтимал.

Ул да түгел, аның карашы үзләренең йортына төште. Солдатның йөрәге «жу» итеп китте, йөгереп килгән җайга кинәт тукталып калды. Күңелне әйтеп аңлаткысыз шом биләп алды. 1930 елдагы йөрәк әрнеткеч вакыйгалар күз алдына килеп басты.

...Аларның гаиләсе Фома авылында таза хәлләләр исәбендә йөри иде. Әтисе Салих, тирә-юньдә дан тоткан балта остасы үзләре өчен алты почмаклы өй өлгерткән иде. Колхоз төзү, кулакларны авылдан сөрү башлангач, алар йортына да Совет активистлары килеп керделәр, өйләренең конфискацияләнүен хәбәр иттеләр. Каршылык күрсәтмәде әтиләре, моның болай бетү ихтималын ачык чамалый иде, ишле гаиләсен җыеп чыгып китте. Аларны кардәш тиешле абзыйлары өйдәш итеп кабул итте. Шул көннән башлап, менә 14 ел инде, кеше өстендә яшиләр, үз нигезләре юк.

Ә йортны сүтеп район үзәгенә алып киттеләр. Фатир итеп файдаланалар, ниндидер җитәкче яши аларның өендә. Аңа ярый, ул кулак түгел булып чыга. Ә ул йортны корган хуҗа үзе, Салих, кеше каршында өйдән-өйгә йөри, гаилә өчен кечкенә йорт салырлык та рәте юк, ревматизмнан интегә, күп вакытын урын өстендә уздыра.

Иреннәрен тешләп куйды Сәлим. Үзенең халәтен аңлап, вакыты чыгып барганны исенә төшерде, атлап китте. Бу минутта аның өчен барыбер, юлы уңмады, бернигә исе китми иде. ..

Ул үзләренең составы янында рельс чистартып йөрүче хатын-кызларга игътибар итте. Аларның берсе таныш шикелле тоелды—аңа.

—Рәхилә апа, син түгелме соң?

Үткән-сүткән хәрбиләргә исе китмәгән хатын-кыз, Труд поселогында яшәүче Моратханова, исемен ишетеп, эшен бүлеп күтәрелеп карады.

—Бәрәч, Сәлим?!...Син?!

Кардәш тиешле апасы шулай дип куйды да, ни әйтергә белми аптырап басып торды.

—Ничек болай?—диде, ниһаять, аңына килеп.

—Фронтка узып барыш. Безнекеләрнең хәлен белмисеңме, Рәхилә апа?

—Беләм, Сәлим беләм. Монда авылдан килеп эшләүчеләр да бар, әнә арырак.

Ул күргән икенче танышы авылдашы Зәйнелгарәп Галиуллина (хәзер Садретдинова) булып чыкты. Ул авылдан тимер юлга эшкә мәҗбүри китерелгән икән.

—Безнекеләр ни эш бетереп ята анда, Зәйнелгарәп?—Килә-килешкә, сәлам да биреп тормастан шуны сорады солдат.

—Әниеңнәр исәннәр, Сәлим,—диде тегесе. Тагын нидер әйткән иде, паровоз гудогы аны бүлдерде. Состав кузгалу алдыннан бирелгән сигнал иде бу. Сәлимнең үзе урнашкан платформа турына кадәр (экипажлар состав артына тагылган өч товар вагонына караганда үз танклары янында брезент астына күчеп беткәннәр иде) шактый ара әле.

—Минем фронтка китеш, безнекеләргә әйтерсез,—диде Гафуров һәм йөгерә башлады. Юлдашлары да аңа иярде, дөнья хәлен белеп булмый, үз күзләре белән күреп, озатып каласылары килә иде.

—Әйтермен, әйтермен,—диде Зәйнелгарәп йөгергән уңайга.

Паровоз кыска - кыска гына тагын ике кычкыртты, состав дырт итеп селкенеп куйды һәм кузгалды. Платформа өстендә торган иптәшләре Гафуровны тартып алдылар.

Поезд тизлек ала башлады. Сәлим кымшанмый басып тора бирде. Менә күңелгә якын станция артта калды, юл буена утыртылган куаклык башланды. Күңел дулады, йөрәк ярсып типте, кешегә әйтергә оят, елыйсылары килеп китте.

Норлат, инде юл буендагы казармалар, Әхмәт юл разъезды да артта калды. Сәлим платформаның җилдән ышык ягына баскан да хәрәкәтсез калган иде.

—Кер әйдә,—дип чехол астына чакырды аны экипаж командиры.

Тукталыш вакытында танкистлар акчага һәм үзләрендә булган паекка спирт алмашып алганнар иде, шуның белән сыйлананалар.

—Мин соңыннан,—диде Гафуров.

Туган яклар аркылы узу белән бәйле кичерешләреннән һич айный алмады Сәлим. Әтиләренең хәлен белешсә дә, әйтәсен тапшыра алса да, күңеле моңсу иде аның. Платформа өстендә йөзен җилгә каршы куеп баскан да уйга чумып бара. Алдани көтә аны? Туган якны тагын күрергә язганмы, юкмы аңа—кем белә?!...

Ул, әлбәттә, үзенең Богдановның икенче танк армиясенә эләгәсен, Люблин өчен сугышларда катнашасын, Жуков командалыгында Беренче Белоруссия фронты составында Мангушев плацдармында өч ай буе ятасын, Варшава өчен сугышачагын немецларны дөмбәсли-дөмбәсли Балтыйк буена барып чыгасын, Бөек Җиңү көнен исә Берлинда, фашизмның үзәгендә каршылаячагын, сугышчан батырлыклары өчен Кызыл Йолдыз, II дәрәҗә Ватан сугышы орденнары белән бүләкләнәчәген фронттан кайткач үзен озатып калган авылдашлары белән яңадан күрешәсен, бу минутларны кабат-кабат, инде мәзәк хәл итеп хәтергә аласын, фомалыларның аны туган авылындагы «Игенче» колхозына рәис итеп сайлаячагын, бу җаваплы хезмәттә 30 еллар эшлисен, ТССР Югары Советы депутаты итеп сайланасын, Ленин орденына лаек буласын каян күз алдына китерсен. Аны әлегә алда билгесез язмыш, утлы мәһшәр генә көтә, состав шул урынга аларны тизрәк илтеп җиткерү өчен ашыккан сыман тизлеген арттыра бара. Норлаттан чыктылар гына шикелле иде, инде Розовка станциясенә дә җиттеләр. Поезд андый вак станцияләргә туктау кая, тизлеген дә киметеп тормады хәтта. Алдан көтеп барган Сәлимгә Фома авылында ул чакта сакланып калган мәчет манарасы берничә секундка гына күренеп алды һәм шунда ук югалды. Калганнары аның өчен мөһим түгел иде инде, ни булган, буласына күнгән, күңеленнән алдагы язмышы белән ризалашкан иде инде яшь солдат.

Бу станция корылмалары да тәмам күздән югалды. Күңелгә якын туган яклар артта калды. Гафуров моңсу гына шул якка янә күз ташлады да, кабат чакыру көтмичә, экипаж членнары янына Т-34 не каплаган чехол астына керде...

1944 елның май ае бара иде ул чакта.

**Р. АЙЗАТУЛЛИН.**



41 елның июлендә Рогачев янындагы сугыш.



1941 ел. Ленинград блокадасы.



Колхозчылар оборона чикләрен ныгыталар.



**Аларның эшендә җитдилек аеруча кирәкле сыйфатларның берсе. Бирeдә аз гына төгәлсезлек тә кичерелми.**

**«Норлатнефть» нефть һәм газ табу идарәсенең беренче номерлы цехында пластик басымны билгеле бер дәрәҗәдә тоту буенча оператор булып эшләүче Минкасыйм Хәсәнҗанович Әхмәтов шуңа да үз эшенә аеруча җаваплы карый. Эшне ничек үтәү-үтәмәве турыдан-туры аның намусына бәйле бит. Шуны яхшы аңлаганда гына күп нәрсәгә ирешеп була.**

**Минкасыйм Хәсәнҗанович бу цехта 1980 елдан бирле генә эшләсә дә, зур коллективта тиз арада танылып өлгерде. Аны сабыр, таләпчән булуы өчен дә хөрмәт итәләр.**

**Минкасыйм Хәсәнҗанович үзенә ышанып тапшырылган җәмәгать вазифаларын үтәргә дә вакыт таба, техника куркынычсызлыгы буенча җәмәгать инструкторы да ул.**

**Рәсемдә: «Норлатнефть» НГДУсы операторы М.Х. Әхмәтов.**

# „Кондырча" колхозы: кайнар нокталардан репортаж

## Яшелчә кырында— әбиләр

Көн кичкә якынлашуга карамастан, кояш әле шактый кыздыра. Хатын-кызлар шавы белән гөрләп торган кәбестә кырына кергәндә яңа гына утырткан 4—5 яфраклы үсентеләрдән күзне алып булмый. Тәҗрибә күрсәткәнчә, яфраклар саны нәкъ шуңа җиткәч утырту дөрес тә бит: димәк, бик вакытлы утыртыла.

Кара җир эченнән барганда шактый пычранырга туры килде: үсентеләрне юеш җиргә утырталар иде. Бу очракта да кагыйдәләрдән тайпылмаганнар чәчүчеләр. Шуларны уйдан кичереп хатын-кызлар янына килеп җиттек. Бер ишеләре яланаяк: «Кондырча суы җылы, өстәвенә, җир үзе дәвалый да әле»,—диләр. Ул кадәресе турында әйтүе кыен, әлбәттә. Ләкин иң гаҗәпләндергәне башка иде: яулыкларын артка чөеп, күлмәк чабуларын кыстырган хатын-кызлар: Бибиҗамал Гомәрова—73 яшьтә, Мисаль Вәлиева 72 дә, Хәерҗиһан Вәлиева 70 тә, Миннисa Рәхмәтуллина 68 дә, Хәдичә Тямаева, Зәйнелгарәп Халитова һәм Сара Сәмәханова—67 дә, Минегаян Абдуллина 66 да, Рокыя Хөсәенова 64 тә, Затия Әюпова, Минәсма Тямаева, Сәкинә Усманова, Әминә Насыйрова, Фатыйма Гыйләҗева, Миңсылу Гомәрова—болар һәммәсе дә диярлек 55 тән 60 ка якын яшьләрдәге пенсионер хатыннар. Барысы 30лап җыелалар икән. Мәктәп укучылары белән бергә яшелчә кырында 75ләп кеше эшли. 6 гектар җирне биләячәк кырда бүген өченче көн эшлиләр, исәпләре—дүртенче көнгә утыртып бетерергә. Бу урында узган елдагы хәл белән чагыштырып китмичә мөмкин түгел. 6—7 хатын-кыз бер ай мәшәкатьләнәләр. Һәрнәрсәнең үз вакыты бар бит: шундый темпта утырту көз җиткәч үзен сиздерә: кәбестә уңышы башка еллардагыга караганда күпкә начар була.

Быел бу эшне әбиләр үз кулларына алалар. Колхоз кырларында бу хәтле әбине күрергә насыйп булганы юк иде әле. Алар барысы да заманында атлар, хәтта сыерлар җигеп иген иккән, урман кисеп ташыган әбиләр. Ничә дистә еллар авырлыгын җилкәләрендә күтәргән кешеләр хәзер инде лаеклы ялда булырга тиешләр бит. Әмма, юк алар кабат кыр хуҗалары. Бу яктан уйласаң кызганыч тоела, яшьләр юк, колхоз картая бара. Тик шуңа да карамастан, эшнең тукталып тормавы, хәтта яхшырак та башкарылуы куандыра. Үзләре дә зарланырга җыенмыйлар. Көне буе кырда булуларына карамастан, йөзләре көләч, шаярып та алалар.

—Тамагымнан аш үтә башлады. Төне буе йокысызлыктан җәфалана идем. Ничек йоклап, ничек торганымны да белмим. Эшләвем файдага гына, аяк-кулларым сызлаудан туктады,—диләр.

Гомер буе авыр эшкә күнгән аяк-куллар өчен, яңадан шул эшкә кайту дару кебек тәэсир иткән күрәсең. Килүләре дә үгет-нәсихәтләр белән түгел икән. Колхоз рәисе Сәгыйть Ильмухин, халык белән мөнәсәбәтләрнең башка ысулларын тапкан, күңелләренә үтеп керү юлларын өйрәнгән булырга охшый.

—Чакырганны да көтеп тормыйбыз, радиодан рәисебезнең йомшак тавышын ишетәбез дә тиешле урынга йөгерәбез,—диләр апалар.

Баксаң, алар бер яшелчәчелектә генә түгел, колхозның бөтен кайнар нокталарында да эшлиләр икән. Әйтерсең, чынлап торып колхозның үз өсләренә калуын тойганнар. Хуҗалыкта кишер, кызыл чөгендер, кыяр, помидор, суган, бәрәңге дә үстерәләр.

Яшелчәчеләр бригадасына яңа бригадир Минһаҗетдин Әбҗәлимов җитәкчелек итә. Шунда ук 11 ел бригадирлыкта эшләп чыккан Мирза Бакиров та бар. Ул апайларны кәбестә утырту, су сибү серләренә өйрәтергә, тәҗрибәсе белән уртаклашырга килгән. Ә су сибүдә Барый Тямаев та күптәнге остаз.

—Хәзер дымлы җиргә утыртабыз да, аннары дүрт көн су сипмибез әле,—ди ул.

—Быел кәбестә яхшы булырга тиеш, көзгә күрергә килерсез,—дип аңа өстәп куялар яшелчәчеләр.

Яшелчә кыры шундый кулларда булганда, моңа ышанырга була, әлбәттә.

## Йон кырку көчле кулларда

Егетләр чирәмгә чыгып, тиз-тиз генә капкалап алдылар да, кызу-кызу эш урыннарына таба якынлаштылар. 150 бәрән йонын кыркасы калды, шуларны бүген бетерергә, дигән максат тагын да кызулата иде, күрәсең. Колхозда 1100 баш сарыкның йонын кыркырга кирәк иде. Биш егет бүген өченче һәм соңгы көннәрен эшлиләр.

Колхозның йон кырку пункты турында берничә сүз әйтеп үтү мөһим. Аның төзелүенә 20 еллап вакыт узган. Биредә район, республика семинарлары булып үтте. Уникe йон кырку машинасы бар. Авылда ике ир-атның берсе алар белән эшләү серләрен белә. Заманында колхоз рәисе үзе дә республика конкурсында ярышып беренче урынны алган кеше икән. Уникe машина булса да, бары биш егет эшли, чөнки шулар да җитә.

Кайчыларын майлыйлар да, көчле куллы егетләр сарыкны бер ишектән чыгаралар. Биш-алты минут эчендә «җылы туннарын» салдырып чип-чиста ясап, икенче ишектән кертеп җибәрәләр. Шулай көненә 70—75 әр сарык үтә алар кулыннан. Битләреңнән тир ага, күренеп тора: эш авыр, билгә, аякларга бәрә. Гайрәтле куллар сарыкларны әле болай, әле алай әйләндереп кенә торалар. Алар —Наил Фатучев, Илгизәр Тямаев, Фердинанд Ильмухин, Харис Вәлитов—йон кырку тәҗрибәсен шактый туплаган егетләр. Эшләренең нәтиҗәлелеге буенча аларның һәркайсын зур кызыксыну били. Күпме сарык кулыннан үтә, эш хакы да шулкадәр дигән сүз. Бер башка ике сум түләнсә, көненә күпме төшкәнен санавы катлаулы түгел. (Әлбәттә, заманы өчен моны әлләни күп дип булмый). Әгәр дә чиста алынмаса, яисә ашыгып сарыклар җәрәхәтләнүгә дучар булса, бер башка 1 сум 50 тиен, хәтта 1 сумга кадәр кими. Ашыгып, сыйфатсыз алуның файдага түгеллеген беләләр егетләр. Тик рәис әйтүенчә мондый хәлнең күзәтелгәне булмады әле. Каршыда гына эшеңне кабул итүчеләр утыра. Гаяз Тямаев—ревкомиссия рәисе, йонны исәпкә дә ала, классификацияләп тә тора.

—Быел сарыкларның йоннары коры, узган елгыга караганда чистарак та, күбрәк тә чыга,—ди ул. Гата Вәлиев бирeдә механик, кайчылары ватыла калса, ул сакта, йон алуның барышын да күзәтеп тора. Заһирә Халитова һәм Хәтирә Ибәтуллина апалар йонны ташып, киптереп, капчыкларга тутыра торалар.

Караңгы төшәргә вакыт бар иде әле, ә егетләр сәгатьләр белән санаша торганнардан түгел, эшләрен төгәлләп киткәннәр икән.

Ф. ГАЛИМОВА.

## *Газетада басылмаса да*

Редакциягә Яңа Әлмәт авылында яшәүче Н. Шәйдуллинаның кибет эшчәнлеге белән канәгатьсезлек белдереп язган хаты килгән иде. Аның күчермәсен без райпо рәисе Һ. Х. Садыйковка юлладык. Түбәндә аның җавабын бирәбез:

«Әйе, чыннан да Яңа Әлмәт кибетендә хәлвәне өрек җимеше өстәп сатканнар. Сатучы моның өчен коллектив җыелышында тикшерелде һәм җәза бирелде.

Кибеттә катнаш азык-төлек товарлары билгеләнгән норма буенча сатыла, теркәү китабы бар. Вакытлы фактура буенча кайтарылган товарлар исәп-фактура алганчыга кадәр сатылмый. Январь, февраль аенда кайткан шикәр комы белән нәкъ шул хәл була.

Халык депутатларының район Советы башкарма комитеты карары буенча аракы 18 яшьтән башлап һәр кешегә бер шешә бирелә».

● **Балалар музыка мәктәбе башкаручыларының иҗат отчетыннан соң уйланулар**

# Иҗат белән тәрбиялик

Кешедәге бөтен сыйфатларның нигезе балачактан салына. Балалар гаҗәеп табигыйлык, эчкерсезлек сәләтенә ия. Балалар өчен барысы да уеннан башлана. Уен алар өчен сәнгать, ул дөньяны танып белүнең, үзеңнең шул дөньяның бер өлеше икәнлегеңне аңлауның беренче формасы. Балаларыбыз бездән бәхетлерәк, аңлырак, матурлыкны күрә белә торган булып үссеннәр дисәк, без моны аңларга һәм иҗади уен аларның гадәти тормышына әйләнсен, гомер буена беренче ихтыяҗы булсын өчен бөтен көчебезне бирергә тиешбез. Нәкъ балачакта якты, көчле индивидуальлек яисә киресенчә, үзенчәлексез стереотиплык формалаша бит.

Һәркемне туганнары, дуслары, якыннары чолгап алган, һәм шулай дусларча, аталарча ярату, якын кешеңә карата мәхәббәт хисләрен читләтеп үтү мөмкин түгел кебек. Әмма, юк... Күпме кеше шул хисләрне тою сәләтеннән мәхрүм. Моның төп сәбәбе еш кына тормышыбызда хисләрнең ролен бәяләп бетермәвебездә, балалар күңелендә яшьтән үк хисләр үсешенә битарафлыгыбызда. Шул рәвешле табигать биргән хислелек һәм эмоциональлек сүнә бара.

Кешенең эчке рухи дөньясы үсешендә сәнгать белән аралашу бәяләп бетергесез роль уйный. Мәсәлән, бездәге уку процессында балалар музыкаль инструментта уйнауны үзләштереп кенә калмыйлар, иң мөһиме алар—иҗат ияләре. Теләсә нинди, кечкенә генә музыкаль әсәрне өйрәнү өчен күпме хезмәт куярга, ихтыяр көчеңне, ныклыгыңны күрсәтергә, хисләреңне, рухи дөньяңны ачарга кирәк бит. Һәр тәгъбирдә никадәр иҗади эзләнү, матурлыкка омтылу бар. Бу минутларда алар — иҗади биеклекне сиземли башлыйлар һәм аңа җиңел генә ирешеп булмаячагын аңлыйлар. Нәкъ шундый иҗади эшчәнлек, эмоциональ тойгы, рухи тугрылык, битарафлык белән килешмәүчәнлек тәрбияләнә дә бу мизгелдә.

Ниһаять, беренче җиңү. Бала пьеса өстендә эшләүне тәмамлый. Никадәр шатлык, хезмәтеңнән канәгатьлек. Нинди матур моңлы көй икән бит, нинди дулкынландыргыч ноталар, нинди аһәңлелек икән?! Бу чакта аларның йөзләрендә чагылганны язып аңлату мөмкин түгел, иңнәреңә канатлар куйсаң очып китәрләр сыман тоела. Бөтен тирә-якны шундый сихрилек били, ә якыннарың, дусларың, укытучыларың искиткеч әйбәт, ягымлы кебек. Баксаң, көй кешедәге иң нечкә хисләрне кузгата икән. Җырсыз, көйсез зур дөньяга килүче кешегә эмоциональ, эстетик һәм мораль культура турында төшендерүе кыен. Музыка —ул хисләр теле. Музыканы аңламасаң, баштан кичермәсәң, аны тыңларга тирән рухи ихтыяҗ булмаса, дөньяны һәм хисләрне танып белү мөмкин түгел.

Сәнгатькә омтылу максатсыз күңел ачу гына түгел, ә кешенең иҗат мөмкинлекләрен формалаштыру. Ул иң элек иҗади хезмәт, күрү, ишетү, сиземләү, фикерләү сәләтен үстерү коралы. Сәнгать ул калыпка әйләнгән фикерләүне үзгәртә алуга сәләтле иҗат. Бүгенге көндә безнең һәркайсыбызны тәрбия эшенең шул ягы бөтен җитдилеге белән борчырга тиеш.

Балалар музыка мәктәбендә уку процессы, кайбер ата-аналар уйлавынча, «үзе өчен уйнарга өйрәтү белән генә» чикләнми, ә алда әйтелгән бурычларны хәл итүне дә күздә тота. Безнең мәктәптә балалар фортепианода, баянда, гитарада, домбрада, балалайкада, виолончельдә уйнарга өйрәнәләр, ә хореография бүлегендә аларны классик, халык, бал биюләренә һәм тарихи-көнкүреш биюләргә өйрәтәләр.

Безгә укучылар җыю 1 июньнән 15 июньгә кадәр дәвам итәчәк. Теләүчеләр сәгать 9 дан кичке 4 кә кадәр балалар музыка мәктәбе бинасында языла алалар. Музыка дөньясына рәхим итегез!

**Т. БАДЫГИН**, балалар музыка мәктәбе директоры.

# Ит җитештерүгә—җитди игътибар

Соңгы елларда азык-төлек кытлыгы безнең авыл хуҗалыгы эшчәннәреннән аеруча җаваплы хезмәт сорый. Чөнки продукция җитештерү һәм сатуны арттырмый торып өстәлләр муллыгы турында сүз алып бару да мөмкин түгел. Әмма, терлекчеләр хезмәтен, кызганычка каршы, быел ул җәһәттән мактый алмыйбыз.

Быелның 5 ае мәгълүматларыннан күренгәнчә, районда ит җитештерү һәм сатуның торышы зур борчу тудырырлык хәлдә. Ит җитештерү узган ел белән чагыштырганда 19 процентка кимегән, дәүләткә ит сатуның ярты еллык планы да 73 процентка гына үтәлгән. Ә аерым хуҗалыкларда бу сан тагы да түбәнрәк. «Кондырча» колхозында ул 44, «Сөлчә» совхозында 36, «Знамя Октября» да 42, «Чирмешән»дә һәм «Үрнәк»тә 53, «1 нче Май»да 48, «40 лет Победы» колхозында 59 процент кына тәшкил итә. Әгәр бу тармакта эш шул рәвешле барса, районга ит сату буенча еллык планны өзү куркынычы яный. Моның сәбәбе нәрсәдә?

Иң элек ул маллардан тәүлеклек артым алуның тиешле дәрәҗәдә оештырылмавы нәтиҗәсе. Бу мөгезле эре терлекләрдә дә, дуңгызларда да күзәтелә. Аларның беренчесендә артым алу узган ел белән чагыштырганда 64, соңгысында 5 граммга кимегән. Мөгезле эре терлекләрдән тәүлеклек артым алуда «Мамык» совхозы (367 грамм), «Заветы Ильича» (352 грамм), «Алга» (407 грамм), «1 нче Май» (452 грамм), «Чишмә» (470), Синдряков исемендәге колхоз (484 грамм), «Сөлчә» совхозы (425 грамм) аеруча сүлпән эшләделәр. Дуңгызлардан тәүлеклек үсешне чиктән тыш начар алучы хуҗалыклар да бар. «Знамя Октября» колхозында ул 178 грамм, «Алга» да 251, «Сөлчә» дә 224, «Төрнәс»тә 226, Ульянов исемендәге колхозда 228 грамм гына тәшкил итте. Әлбәттә, мондый хәл дәвам иткәндә еллык күрсәткечләрнең яхшырасына өмет тоту кыен.

Ит җитештерү һәм сату торышына тискәре йогынты ясаган факторлар тагы да бар, әлбәттә. Шуның берсе—малларның үлем-китеменә юл кую. Быелның 5 аенда районда мөгезле эре терлекләр арасында барлык көтү әйләнешенең 2,17 проценты кадәр үлем күзәтелә, дуңгызларда бу сан 2,09, ә сарыкларда 2,89 процент исәпләнә. Боларны саннарда күрсәтә алсак, шактый гына түгәрәк цифрлар барлыкка киләсен чамалау кыен түгел.

Әйдәгез, берничә хуҗалык мисалында гына булса да аларны карап үтик. «Знамя Октября» колхозында быел 34 баш (3,7 процент), мөгезле эре терлек, 81 баш (5,8 процент) дуңгыз, «Мамык» совхозында 52 баш (3,98 процент) мөгезле эре терлек, 82 баш (5,6 процент) дуңгыз, «Алга» колхозында 31 баш (1,97 процент) дуңгыз һәм 208 баш (11,7 процент) сарыклар, Кузнецов исемендәге колхозда 48 баш (5,36 процент) мөгезле эре терлек, «Восход»та 61 баш (5,0 процент) дуңгыз үлүенә юл куелган.

Болар, әлбәттә, без ирешә алмаган процентлар, саннарны тагы да борчылырлык дәрәҗәгә китерәләр.

Үрчем алуда да уйланырлык саннар бар. Быелның 5 аенда бозаулар алу 336 га, ягъни һәр 100 баш сыерга исәпләгәндә 2 гә кимегән.

Бу җәһәттән «Комбайн», «Заветы Ильича», «Чишмә» колхозлары һәм «Мамык» совхозында хәл аерата мөшкел. Биредә 70, 78, 80, 100 бозау узган елдан ким алынган.

Үткән ел белән чагыштырганда бәрәннәр алуда да аерма безнең файдага түгел.

Ул 1347 баш, 100 сарыкка күчергәндә 9 башка азрак алынган. Әлеге юнәлештә XXI партсъезд исемендәге колхоз «рекорд» куя: бәрәннәр саны биредә 229 башка ким. «Путь к коммунизму» колхозында бу сан 200, «Алга»да 102 баш исәпләнә.

Дуңгызчылыкта исә бу хәл «Төрнәс» совхозында (631 башка ким), «Москва» (291гә), «Знамя Октября» (281гә), «Комбайн» (346 га) колхозларында тамыр җәйгән.

Малларның үлем-китеменә юл кую һәм үрчем алуның түбән булуы җәмәгать терлекләренең баш саны кимүгә китерә.

Быел районда мөгезле эре терлекләр узган ел белән чагыштырганда 6 процентка азайды. Хафизов исемендәге колхозда ул 20, «Восход»та 16, «Комбайн»да 14, «40 лет Победы»да 13, «Москва»да 13, «Үрнәк»тә—12, «Сөлчә» совхозында 15, «Мамык» совхозында 15 процентка кимеде. Шундый ук хәл дуңгызчылыкта да хөкем сөрә. «Москва» колхозында дуңгызларның баш саны быел 40 (!), «Мамык» совхозында 33 процентка тиклем кыскарды, «Комбайн», «Сөлчә» дә ул 23—11 процент тәшкил итә, район буенча исә 6 процентка җыела.

Сарыкларның баш саны кыскару да «Алга», Хафизов исемендәге, XXI партсъезд исемендәге колхозларда 23—19 процентка кадәр җитә. Бу күрсәткеч район буенча да шактый югары—8 процент тәшкил итә.

Ә ит җитештерүне арттыру резервлары, уйланган кешегә бар. Бу җәһәттән бер нәрсәне әйтеп китү дә бик кирәк. «Үрнәк», «Кондырча», «Чирмешән», Кузнецов исемендәге колхозлар ел башында хуҗалыкта дуңгызчылык белән шөгыльләнергә керешәчәкләре турында нык сүз алып барганнар иде. Алар әйбәт беләләр: шуңа тотынмый торып, итчелекне җайга салу мөмкин түгел. Әмма бу әлегәчә сүздә кала бирә, хуҗалыкларның берсе дә аны быел гамәлгә ашыра алмадылар. Мондый акрынлык һич гафу ителмәслек хәл әлбәттә.

Күргәнегезчә, ит җитештерү һәм сатуның торышына тискәре йогынты ясаган җитешсезлекләр аз түгел. Һәр хуҗалык үз эчендә аларның сәбәбен ачыклап, кыска срокларда аларны төзәтү юлларын кайгыртырга тиеш. Шул чакта гына без ит муллыгы өчен көрәшнең нәтиҗәлелегенә ирешергә, бу төр продукцияне дәүләткә сату планын үтәүгә исәп тота алачакбыз.

**Х. ФӘТХУЛЛИН,**
авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе зоотехнигы.



## Алдынгыларның берсе

**20 елдан артык савучы булып эшләү дәверендә осталык та, тәҗрибә дә туплады Зөлфия Мөшәрәповна Ибраһимова. Эшкә бирелгәнлеге, тирән җаваплылык тоеп эшли белүе, үз-үзенә таләпчәнлеге юл ачты да аңа осталыкка. Шул ук вакытта яшьләрчә өлгергәнлеген, җитезлеген дә һич җуймый Зөлфия Мөшәрәповна. Хәзер, җәмәгать маллары җәйләүгә чыгарылгач, терлекләрдән мул продукция алу өчен көчен кызганмый, бу көннәрдә үз группасындагы сыерлардан 12 шәр килограмм сөт сава.**

**Җәйләү чорын мул сөт чоры. Хуҗалыкның барлык савучылары да бу чорда маллардан күп продукция алырга омтылалар һәм көнне-төнгә ялган эшлиләр.**

**Рәсемдә: XXI партсъезд исемендәге колхоз савучысы З. М. Ибраһимова.**

**ХЕЗМӘТЕН ХӨРМӘТЛӘП**

Совет органнарында озак еллар нәтиҗәле эшләгәне өчен Октябрь районының Кычытканлы авыл Советы рәисе Фаикъ Нургали улы НУРГАЛИЕВ Татарстан ССР Югары Советы Президиумының Мактау грамотасы белән бүләкләнде.

# Йорт салуның ние бар?

Борын-борын заманда... түгел, быелның май ахырында, җиде диңгез артында түгел, Норлатның үзәк больница белән янәшә яңа өлешендә, өянкеләр янындагы кечкенә күл буенда ямь-яшел йомшак чирәмлек бар иде. Көннәрдән бер көнне бу үзәнлектә куәтле җир казу машинасы пәйда булды. Ул әлеге яшел хәтфәне ертып-ертып канау казырга кереште. Бер көн эчендә йорт нигезен хәтерләткән канаулар челтәре әзер дә булды. Ул да түгел, тимер-бетон балкалар китереп бушаттылар. Әлеге яшел болынлыкта бала-чаганың гөр килеп уйнаячагы турында хыялланган һәм күңеленнән ләззәт кичергән ата-аналар башта бу хәлгә өнсез калдылар, ә инде шул рәвешле кемгәдер шәхси йорт нигезе салына башлаганлыгын белгәч, кызыксыну һәм нәфрәтләнү давылы купты.

—Безнең балалар кайда уйнарга, ни белән мәшгуль булырга тиеш икән? Аларны бит өйдә бикләп тотып булмый!

—Чеби генә түгел, бер почмакка читлеккә ябa алмыйсың!

—Урам сукбайлары әллә каян килеп чыкмый ул!

—Ә кечкенәләрне нишләтергә? Урам ташына утыртып уйнатыргамы? Машина-мазар бәрдереп китмәгәе дип дер калтырап яшибез. Шул рәвешле фикерләр бер-берсен тулыландыра торды. Әмма әлегә бушка әйләнгән сүз тегермәненнән мәгънә чыкмасын аңлаган кешеләр—дөресрәге, Карл Маркс урамының әлеге төзелеш башланган мәйдан каршындагы 2, 4, 6 нчы йортларда яшәүчеләр шушы ишегалды халкының җыенын үткәрделәр. Җыенга халык депутатларының Норлат шәһәр Советы рәисе, депутат М. М. Фәррахов та чакырылган иде. Дөрес, җыен булачагын хуплаган кешеләрнең шактые бу манзараны читтәнрәк күзәтүне мәгъкул күрде. Әллә аларны әлеге төзелә торган шәхси йортның хуҗасы—районның күренекле, ихтирам казанган врачлары Таһировлар булу (һәм аның бу җыенда катнашуы) уңайсызландырды, әллә шәһәр Советы рәисе белән очрашу шикләндерде (ни генә дисәң дә кирәк-кирәкмәскә «хуҗалар» күзенә кылчык булып кадалмавың хәерлерәк диделәрме), әмма алар җыен таралганчы урамда булуларына карамастан, якын килеп сөйләшүгә кушылмадылар. Югыйсә, җыенга кадәр алар да бу мәсьәләдә башкаларга теләктәш булганнар икән...

Ярый, хуш. Бусы һәркемнең үз намус эше. Ә менә күтәрелгән мәсьәләне намус белән, кешеләр өчен хәл итү кемнең эше икән соң?

**Җыен барышында ишетергә туры килгән сүзләр төрлечә булса да, аларның асылы бер генә фикергә кайтып калды—ни өчен шәһәр Советы гади халык белән исәпләшми? Ни өчен бездә: «Бөтен яхшылыкны—балаларга!—диләр, ә чынлыкта бөтен яхшыны районның аксөякләренә бирәләр? Һәм шуның белән ул кешеләргә карата да халыкта тиеш булмаган кире мөнәсәбәт тудыралар?**

Әйтик, шул ук төзелә башлаган йорт хуҗалары—Таһировларны гына алыйк. Аларны ихтирам итмәгән, үз гомерендә алардан белгеч буларак ярдәм күрмәгән кеше аздыр бездә. Кемнәрдер әле үзенең яки баласының тормышын саклап калган өчен гомере буе рәхмәт укыйдыр. Җыенда катнашучылар үзләре дә (күңелләрендәге ихтирам хакына дип уйлыйм): «Мөмкинлеге булгач, төзесен, әлбәттә. Бер сүзебез юк. Әмма нигә безнең балалар хакына хәл итәсез бу мәсьәләне?!»—дип рәнҗеделәр. Әйе, Таһировлар урынында теләсә кем—Иванов, Сидоров һ.б. берәү булырга мөмкин иде. Сүз дә юк, сайланган урыны бик отышлы. Ләкин әгәр шәһәр Советы рөхсәт бирмәсә, Таһиров та, Иванов та—беркем дә әлеге урынга барып хан сарае төзетә башламый бит! Нинди генә күренекле шәхес булса да. Шулай түгелмени? Районда баш архитектор, аның ярдәмчеләре, махсус бүлек бар. Нәрсә белән шөгыльләнәләр алар? Шәһәребез үсә, районыбыз яңара дип сөенгән булабыз. Сөенергә иртәрәк түгелме икән? Менә күз алдындагы иң гадәти очрак бу. Бер-беренә терәп 2 шәр катлы өч яңа, заманча йорт салынган. Бүгенге көндә шул йортларда 180 ләп бала яши. Күченгән гаиләләр—яшьләр, балалар санының артуы көтелә. Ә шул ишегалларын берләштергән бер уен мәйданчыгы планда каралмаган! Ул гына да түгел, әлеге йортлар моннан 2 еллап элек үк: «Бөтен шартлар тудырылган», —дип кул куелып кабул ителүгә карамастан, анда яшәүчеләр бүген дә сусыз, газсыз, кер эләргә урын тапмый тилмерәләр. Әлбәттә, эштән кайтуга су эзләп яки ерактан ташып, җылытып—мең мәшәкать белән юган кереңне эләр урын тапмасаң яки яртылаш кибүгә аңа кырыеннан үткән машина тузан өрдереп китсә, урамнан балаң елап кайтып керсә—монда инде беркемнең дә тәрәзә каршында ай үсәсен көн үскән гүзәл бинага карап рухланырга күңеле җитмәс. Хәтта аның хуҗасы кем генә булса да...

Үз гомерендә күп тапкырлар алданган халык шәһәр Советы рәисенең төче вәгъдәләренә әллә ни өмет багламый. Шулай да алар күңелендә әлегә яктылык бөтенләй сүнмәгән икән: —«1991 елда яшибез, ләбаса! Бәлки җитәкчеләрдә аз гына иман заты калгандыр—вәгъдәләрендә торырлар?»— дигән сүзләр дә ишетергә туры килде. Көтеп карыйк әле, иптәшләр, алайса. Чынлап та, аз гына булса да үзгәртеп кору шаукымы тимәдеме икән? Әгәр без көткән арада теге болынчыктагы шәхси йорт төзелеп бетмәсә...

**К. ҖАМАЛЕТДИНОВА.**

● **Редакциягә килгән хатларга күзәтү**

# Эндәшмәвең—алтынмы?

Май аенда редакция газета укучылардан 187 хат алды. Шулардан 167 хат газетада мәкалә яки аңа нигез буларак файдаланылды. Болар—хезмәт коллективлары һәм аларның эшләре, хезмәт кешеләре һәм аларның уңышлары, район-шәһәр яңалыклары, аерым язмышлар, иҗат дөньясы һәм башка темаларны үз эченә алган хәбәрләрдән гыйбарәт иде. Моннан тыш безгә бу айда дәгъвалы 20 хат килде. Боларның 4 се районда автобуслар хәрәкәте һәм автовокзал эшчәнлеге мәсьәләләренә кагыла иде. Без аларны Норлат автовокзалы начальнигы И. С. Каняфинга юлладык. Халык депутатларының Норлат шәһәр Советы рәисе М. М. Фәрраховка чара күрүне, хәл итүне сораган 4 хат җибәрелде. Аларда, нигездә, сүүткәргечләр, урамнар төзеклеге мәсьәләләре күтәрелгән иде. Авыллардагы тормыш-көнкүреш хәлләрен тәнкыйтьләгән хатлар авыл, поселок Советларына юлланды.

Югарыда исемнәре аталган җитәкче иптәшләр бу үтенечле хатларга ничек карыйлар соң диярсез. Төрлесендә мөнәсәбәт төрлечә шул. И. С. Каняфин, мәсәлән, җибәрелгән хатларның һәммәсенә бер атна эчендә җавап та бирде (бер җавабы 30 май санында басылды, калганнары буенча да эш алып барыла). Ә менә М. М. Фәрраховка юлланган хатлар майныкылар гына түгел, хәтта апрельнекеләр дә бүгенгәчә җавапсыз кала киләләр. Мәсәлән, шәһәрнең Карл Маркс урамында яшәүче Сергеевлар гаиләсеннән килгән үтенеч хаты иптәш Фәрраховка 22 апрельдә җибәрелгән булган. Аннан соң бу хакта ашыгыч җавап көтүләрен искәртеп, ике тапкыр кисәтү кәгазе дә җибәрдек. Әмма һәммәсе суга төшкән таш кебек юкка чыкты. Нинди генә мәсьәлә булса да, ай ярым эчендә бер фикергә килерлек һәм уңай яки кире җавап бирерлек вакыт узды, ләбаса. Нәрсә бу? Югары постка оялаган җитәкченең «вак-төяк» мәсьәләләр белән вакланып тормавы, «юк-бар»га энергиясен, сәләтен сарыф итмәве, халык тарафыннан сайланган депутатның халыкка мөнәсәбәтеме, редакция белән исәпләшмәвеме, әллә кулыннан эш килмәүме? Һәрхәлдә, 4—5 үтенечнең берсенә генә булса да җитди мөнәсәбәт күрсәтергә тиеш иде шәһәр рәисе.

Елаурда яшәүче сугыш ветераны, I группа инвалид Н. И. Сиплатовның телевизор төзәттерү турындагы үтенеч хатын 8 майда ук инде халыкка көнкүреш хезмәте күрсәтү буенча район производство идарәсе начальнигы Р. С. Хәмидуллинга юллаган идек. Аннан да бүгенгәчә җавап алганыбыз юк. «Сүзең көмеш булса, эндәшмәвең—алтын»,— диюен халык. Әмма бу җитәкчеләр үзләренең игътибарсызлыгы белән халыкның аларга булган алтын өметен, ышанычын юкка чыгаралар түгелме?

Әлеге хат авторлары бүгенге көндә дә җавап көтәләр. Һәм бу табигый хәл. Безнең халыкның, бигрәк тә авылларда яшәүчеләрнең соңгы чиккә җитмичә редакциягә хат яза торган гадәте юк. Әгәр кеше каләм-кәгазьгә тотынырга батырчылык иткән икән—бу инде аның чарасызлыктан гаҗиз булуы дип аңлыйк. Мәсьәләгә дә шундый ук җитдилек белән карасагыз иде, җитәкче иптәшләр!

Бу яктан район потребительләр җәмгыяте рәисе Һ. Х. Садыйковның редакциядән кергән хат-үтенечләргә, халык зарына игътибарлы булуын әйтәсе килә. Җитди сигналлар булганда, коллективта уртага салып сөйләшү, урынга барып тикшерү, гаеплеләргә карата тиешле чара күрү кебек эшләр оештырыла. Һәм бу хакта без дә, газета укучы да хәбәрдар була (18 май, 4 июнь саннары).

Моннан тыш редакция почтасында врачларга, шәфкать туташларына хезмәтләре, күркәм мөгамәләләре өчен рәхмәт белдергән хатлар бик еш очрый. Хөрмәтле укучыларыбыз! Без сезнең күңелегезне аңлыйбыз, сезнең өчен сөенәбез, әмма бу изге ниятле, олы теләкле хатлар бик күп, һәм аларны газета битләрендә урнаштырып бетерү мөмкин түгел. Сез, сүз берләшкәндәй, һәммәгез дә бер үк эчтәлектәге сүзләр язасыз. (Бу, әлбәттә, аңлашыла да). Бастырган очракта да алар берсен-берсе кабатлар гына иде. Шуңа күрә без бу хатларны район үзәк шифаханәсе баш врачы З. А. Шабаевка юллыйбыз һәм әлеге хатларның эчтәлеге белән дәвалаучы коллективны таныштыруларын үтенәбез.

Май аенда редакциягә килгән хатларның язмышы менә шундый. Сезнең белән бергә без дә борчылабыз, ашыктырабыз, кемгә дә булса уңай җавап бирергә, кемнедер сөендерергә теләгебез зур. Әмма бу омтылыш күп очракта югары җитәкчеләрнең битарафлыгына, гамьсезлегенә бәрелеп туктап калырга мәҗбүр. Әмма без халык мәнфәгате өчен көрәшебезне туктатырга җыенмыйбыз. Языгыз, хәбәр бирегез, үзегез килегез! Бергә яшик, тормыш яктылыгы өчен бергә көрәшик!

**Редакциянең хатлар бүлеге.**

## *Котлыйбыз!*

**Зирекле авылында яшәүче кадерле әниебез Гамбәр Котдус кызы Шәрәпованы туган көне белән котлыйбыз. Исәнлек-саулык, озын гомер, сөенечләр телибез.**

**БАЛАЛАРЫ, ОНЫКЛАРЫ.**

# Өзелгән гомерне нишләтик

Соңгы вакытта юлларда транспорт һәлакәтләре, фаҗигаләр ешайды. Май аенда гына да 6 юл-транспорт вакыйгасы булды. Нәтиҗәдә 2 кеше вафат булды һәм 4 кеше яраланды.

19 майда Колбай Мораса авылы кешесе Н. Ибәтуллин исерек хәлдә мотоцикл белән идарә итә. Әлмәт авылы белән Колбай Мораса арасында ул тизлеген арттыра һәм мотоцикл әйләнеп каплана. Нәтиҗәдә транспорт хуҗасы тән җәрәхәте ала.

23 майда Норлатта яшәүче А. Воскобойник эчкән килеш ЯВА-350 мотоциклы белән баганага бәрелә һәм аның гомере өзелә.

1 июньдә «Агропромхимия» берләшмәсе эшчесе А. Петров һәм МПП эшчесе А. Вертушкин берләшмә җитәкчелеге тарафыннан контроль булмаудан файдаланып, К-700 тракторында Андреевка авылына «сәфәргә» китәләр һәм ике көн буе анда эчкечелек белән шөгыльләнәләр. Бернинди максатсыз-нисез Богдашкино авылы белән Андреевка арасында сәяхәт кылып йөриләр. Әмма, ни гаҗәп, бу хакта милициягә хәбәр итү берәүнең дә башына кереп карамый. 3 июнь көнне бу ике «ахирәт» тизрәк шәһәргә кайтып тракторны гаражга куярга ниятлиләр һәм юлга чыгалар. Әмма кайту юлында сәгать 4 белән 5 арасында трактор әйләнеп каплана. Бик каты имгәнү сәбәпле, икесе дә шунда ук җан бирәләр. Әлеге «сәяхәт» шундый зур фаҗига белән тәмамлана.

Соңгы вакытта оешма, хуҗалык җитәкчеләренең шоферларның шәхси үтенече буенча, төп сәбәбен ачыклап тормастан, аларга транспорт белән эштән китәргә, ял көннәрендә үз максатларында йөрергә рөхсәт итүләрен күргәләргә туры килгәли. Кызганычка каршы, күп кенә иптәшләр шимбә һәм якшәмбе көннәрендә шоферга үз максатларында йөрү хокукы махсус түгәрәк печать белән расланган путевка рәвешендә һәм предприятие, оешма, хуҗалык җитәкчесенең үз рөхсәте белән генә бирелүен белмиләр.

Югарыда сөйләнгән трактор белән булган вакыйга буенча тикшерү эше бара. Урындагы җаваплы кешеләр үзләренең эшкә салкын караулары өчен тиешле катгый җәзаны алырга тиешләр.

Гаеплеләр җәзасын алыр, әмма өзелгән гомерне кайтарып булмавы бик аяныч.

**Х. ӘЮПОВ,**
ГАИ начальнигы, милиция капитаны.

# Эт—ул йорт хайваны

Тирә-як мохитне саклау бүгенге көннең иң мөһим мәсьәләсе итеп санала хәзер. Бу турыда төрле дәрәҗәдәге җыелышларда, Югары Совет утырышларында да сүз бара, матбугат язмаларында да ул проблема күтәрелә. Борчылырлык мәсьәләләр дәрестән дә бар. Аны табигатьне саклау оешмалары яки һәртөрле законнар белән генә хәл итүгә һич ирешеп булмый. Табигатьне кадерсезләүгә иң элек без үзебез—кешеләр юл куймаска тиеш.

Әйтик, этләрне алыйк. Алар гомер-гомергә кешенең иң тугры, алыштыргысыз ярдәмчеләре булганнар. Нинди авыр хәлдә дә үз хуҗаларын ташламаган этләр турында легендалар язылган, аларның акыл иясе булуына беркем шикләнми. Ә без шул акыл ияләрен, тугъры дусларыбызны ни хәлдә асрыйбыз соң?

Эт—иң элек йорт хайваны. Ул йорт хайваны итеп теркәлгән, шулай булып калырга тиеш тә. Ә бүген аларның күбесе яраткан хуҗаларының «мәрхәмәте» аркасында урам этләренә әйләнеп беттеләр. Урамга чыксаң төркем-төркем иясез этләр йөри. Алар кош-кортны өркетә, бала-чаганы куркыта, шунда ук зыян салып китүе дә бик ихтимал.

Без яшь чакта әниләр безне урамга озатканда «кара аны, эт тизәгенә баса күрмә», диләр иде. Юкса икенче көнне үк чабата төбенең тишелеп чыгасын көт тә тор. Соң, чабата тишкән эт тизәге башкага да зыян бит инде.

Хөрмәтле укучы, эт экологиягә зыян китерә дип, этләрне юк итәргә өндәвем түгел. Эт кешенең дусты, эт—йорт хайваны. Ул йорт хайваны булып калырга тиеш тә. Аның теләсә кая иясез йөрүенә юл куймыйк, аны ияле итик, якын дустыбызны караган шикелле аның турында кайгыртыйк. Бу экология ягыннан бер файдалы булса, кешелеклелек, мәрхәмәтлелек ягыннан икенче өлге булыр.

**И. ШӘЙХИЕВ.**
Зирекле авылы.



**ПОЛЬША.** **Генетика институты Варшавада пробиркада эмбрион үстерү алымы белән сарыклар үрчетү ысулын эшләде. Йомыркаларның өлгерү процессы, аның аталандырылуы һәм эмбрион үсешенең беренче стадиясе «Ин витро» алымы белән үтә.**

Яңа алым иң яхшы нәселле терлекләр чыгаруга булышлык итәчәк.

Рәсемдә: Польшада «Ин витро» алымы белән үстерелгән беренче сарык—Примус.

**ТАБЫЛДЫКЛАР**

«Дружба» урамында акча янчыгы табылды. Югалтучының Дружба урамы, 64 йорт, 37 фатирында яшәүче Г. П. Нестерюкка мөрәҗәгать итүе сорала.

**ӨСТӘЛЕНӘ**


**БЕЛДЕРҮ**

**«Норлатнефть» нефть һәм газ чыгару идарәсенең Норлат автомобиль юллары идарәсенә ашыгыч рәвештә каравылчылар (вакытка карап-премиаль түләнә), бульдозерчылар, Т-150 тракторчылары, КамАЗ йөртү өчен шоферлар (түләү—эш башыннан-премиаль, 15 процент территориаль коэффициент өстәлә), КАВЗ-685 автобусына шоферлар (түләү—вакытка карап-премиаль, 15 процент территориаль коэффициент өстәлә), баш механик, техника куркынычсызлыгы буенча инженер (оклад—штат расписаниесе буенча) кирәк.**


**Район эчке эшләр бүлеге каршындагы сакчылык бүлеге коллективы бүлек милиционеры Ильяс Туктаровның энисе**

**ГӨЛСАНИЯ ХӘКИМҖАН кызы ТУКТАРОВАның**

**вакытсыз үлүен хәбәр итә һәм аның гаиләсенең, туганнарының тирән кайгысын уртаклаша.**


**МӨХӘРРИР Ә. У. АБДУЛЛИН.**

**Учредительләр— халык депутатларының Октябрь район Советы, КПССның партия оешмасы.**

**Газетада язмалары басылган авторларның фикерләре бу әле редакция фикере дигән сүз түгел.**

**РЕДАКЦИЯНЕҢ АДРЕСЫ: 423000, Норлат шәһәре, К. Маркс урамы, 19.**
**ТЕЛЕФОННАР: мөхәррир—2—12—14, 2—22—81, мөхәррир урынбасары—2—10—44, рус теленә һәм чуваш теленә тәрҗемә буенча мөхәррир урынбасарлары—2—15—63, социаль-экономика бүлеге— 2—22—51, җаваплы секретарь—2—14—16, хатлар бүлеге һәм бухгалтерия—2—18—67.**

Газетаны Нурзия ФӘСХЕТДИНОВА җыйды. АСИЯ МОРАТХАНОВА верстка ясады. Фирдания ХУҖИӘХМӘТОВА басты. Корректор—Рәзинә ШӘЙХУЛЛИНА.

**«Дуслык» газетасы атнаның сишәмбе, пәнҗешәмбе, шимбә көннәрендә чыга һәм рус, чуваш телләренә тәрҗемә ителә.**
**Нәшрият, полиграфия һәм китап сәүдәсе буенча ТССР Дәүләт комитетының Октябрьның 50 еллыгы исемендәге Норлат-Октябрь типографиясе.**
**Күләме—1 басма табак. Заказ 71. Тираж 3411.**